## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«23» март 2022 ел Яр Чаллы № 893

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» 128 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын финанслау суммасының артуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 15 февралендәге 244-р номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» 128 номерлы карарына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 2022 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә финанслау күләмен 265600,00 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:
3.

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2021-2023 елларда 11 201 168,70 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда – 7 267 568,7 сум;<br>2022 елда – 2 099 600сум; |

| | |
|---|---|
| | 2023 елда – 1 834 000 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

4. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру чараларының II «Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар» бүлеге «Район мәгариф учреждениеләренең спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру, Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ бүлекләренең матди базасын ныгыту» пунктына 265600,00 сум күләмендә финанс средстволарын кушымта нигезендә өстәргә.

5. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның мартындагы 893 номерлы карарына кушымта

**«2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | Барлыгы | | |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 1. | Район мәгариф учреждениеләренең спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру, Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ бүлекләренең матди базасын ныгыту | 170617 | 170617 | 170617 | 511851 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| 2. | | | 265600 | | 265600 | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |